ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**27.11.2025** **Чистай шәһәре** **№ 568**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 15 маендагы 178 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 декабрендәге 307-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 2549-р номерлы боерыгы нигезендә, Исполнительный комитет Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2024 елның 15 маендагы 178 номерлы карары белән расланган «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү «муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 15 маендагы 178 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 мартындагы 94 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.11.2025 ел, № 568
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.05.2024 ел, № 178
карарына 2 нче кушымта

2025 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | ел дәвамында | 1093,95 |
| 2 | Спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | ел дәвамында | 135,00 |
| 3 | Югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләүләр | ел дәвамында | 3012,00 |
| 4 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларының шайбалы хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, шайбалы хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программасын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 418,4 |